Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Илбәк авылы № 18 «16» март 2026 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 июнендәге 31 номерлы карары белән расланган (18.10.2016 ел № 37, 19.09.2017 ел №60, 12.02.2018 ел №78, 30.12.2019 ел №147, 24.04.2020 ел №153, 11.10.2021 ел №37, 06.04.2023 ел №77, 25.09.2023 ел №91, 22.01.2024 ел №102, 28.11.2024 ел №127, 22.05.2025 № 145 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 июнендәге 31 номерлы карары белән расланган (18.10.2016 ел № 37, 19.09.2017 ел №60, 12.02.2018 ел №78, 30.12.2019 ел №147, 24.04.2020 ел №153, 11.10.2021 ел №37, 06.04.2023 ел №77, 25.09.2023 ел №91, 22.01.2024 ел №102, 28.11.2024 ел №127, 22.05.2025 № 145 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 бүлекләрне гамәлдән чыгарырга.

1.2. 5 бүлекнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә: «Әлеге пункт белән каралган унитар предприятиеләрнең, акционер җәмгыятьләрнең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына) кертелгән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында тәкъдим ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.К.Галимҗанова